Республика Татарстан
Глава Абалачевского сельского
поселения Менделеевского
муниципального района
ул. Центральная д. 35, помещ.1, д. Абалачи
Менделеевский район, 423657

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Абалач авыл җирлеге
Башлыгы
Үзәк урамы, 35, бина 1, Абалач авылы,
Менделеевск районы, 423657

тел./факс (85549)3-65-49 Email: Abal.Men@tatar.ru

10.11. 2023 ел № 1

Постановление Карар

2024 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Менделеевск муниципаль районы Абалач авыл җирлегенең Тагай авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Абалач авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә,

Карар бирәм:

1. 2023 елның 20 ноябре 15.00 сәг.Абалач авыл җирлегенең Тагай авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану буенча гражданнар җыены уздырырга.
2. Гражданнар җыены уздыру урыны итеп Тагай авылы, Урман асты урамы буенча урнашкан терлекчелек йортын билгеләргә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«2024 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районы Абалач авыл җирлегенең Тагай авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә билгеләргә, югары һәм урта уку йортларының көндезге бүлегендәге студентлардан тыш һәм алынган

акчаларны жирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә сез ризамы?

- Су насосы сатып алу – 2 данә
- Тагай авылы юлларын карап тоту (кыш көне кардан чистарту)
- Җәй көне территориядә үләннәрне чабу (ягулык-майлау материаллары, триммер өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча хезмәткә түләү)

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында - www.mendeleevsk.tatar.ru «Абалач авыл җирлеге» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә

Абалач авыл җирлеге башлыгы Р.Н. Сиражетдинов